*1 слайд – Ш.Зәки*

Шагыйрь, галим һәм укытучы Шәмсетдин Суфый Зәки үзенең эшчәнлеге, поэтик таланты, зирәклеге белән бик күп кешеләрнең, күренекле галим-әдипләрнең игътибарын үзенә тарткан. «Зәкилектә зәки, гамил вә камил», - дип яза аның турында Гали Чокрый. Риза Фәхретдинов әдипне еш кына белем-зирәклекнең өлгесе, эталоны дип карый һәм аны Шәрыкның бөек шагыйрьләре Әл- Мәгарри (937-1057) һәм Фозули (1494-1556) белән тиңли. «Шәмсетдин Суфый, Багдад Фозулисы булмаса да, Урал-Волга буйларының, иң дөрестә безнең Фозулиемыз идекендә шөбһә юк», - ди ул.

Шәмсетдин Зәки Зәк-Ишмәт авылында дөньяга килә. Ул тумыштан сукыр була. Риза Фәхретдинов һәм аңа таянып башка галимнәр Шәмсетдин Зәки кече яшендә үк сукырая, дип язалар. Чынлыкта исә шагыйрь тумыштан ук сукыр була.

Бу хәл, әлбәттә, ата-ананы кайгыга сала, әмма нишләсеннәр? Сабыр итәргә, бу хәлгә күнәргә, улларының сәламәтлеген теләргә генә кала.

Малайга «дин кояшы» мәгънәсендә булган «Шәмсетдин» исеме бирәләр. Соңрак, иҗат юлына баскач, шагыйрь бу исемне поэтик тәхәллүсе итеп тә кулланачак. Икенче тәхәллүсе исә аның - Зәки. Бу кушамат туган авылына нисбәтән алынган.Әдәбиятта һәм фәндә шагыйрь «Шәмсетдин Зәки» дип кенә түгел, ә «Шәмсетдин Суфый Зәки» дип тә йөртелә. «Суфый» кушаматы каян килгән соң? Беренчедән, татар-башкортларда укымышлы сукыр кешеләрне «Суфый» дип атау гадәте элек-электән бар. Икенчедән, Ш.Зәки суфыйчылык идеяләре белән дә мавыккан: хәтта ул Эстәрлетамак тирәсендәге Җиргән авылында яшәүче мәшһүр суфый Толун Хуҗага тапшырылып, аны үзенең шәехе дип тә таныган.Шагыйрьнең бу шәехкә багышлап язган фарсыча шигыре дә мәгълүм. Шәкертләре һәм замандашлары аны еш кына «Суфый хәзрәт», «Суфый» дип йөрткәннәр. Бераздан «Суфый» атамасы, әдәбиятка һәм фәнгә дә күчеп, шагыйрь псевдонимнарының берсенә әверелгән.

Булачак шагыйрь үзенең хәтере, зирәклеге белән кече яшьтән үк күпләрне таң калдыра. Зәгыйфь дип исәпләнгән баланың көчле табигый сәләте, әлбәттә, ата-ананы куандыра. Алар кечкенә Шәмсетдинне тәрбияләүгә, аның зиһенен баетуга, һөнәргә өйрәтүгә күп көч түгәләр. Гарәп, фарсы һәм төрки телләреннән тәүге сабакларны, ислам диненнән һәм башка фәннәрдән башлангыч мәгълүматларны булачак шагыйрь әүвәл әти-әнисеннән ала. Бераздан ул энесе Хаҗимөхәммәд белән белән бергәләп үз авылыбыз мәдрәсәсенә йөри башлый.

13 яшьләргә җиткәч, Шәмсетдин үзләреннән 30 чакрым ераклыктагы Өтәч авылына барып, Котлыкилде мәдрәсәсендә укый башлый.Сау-сәламәт шәкертләр белән бергә яши, бергә сабакка йөри. Сукырлык, фәкыйрьлек /*әтиләре үлгәннән соң аларның томышы гаять авырлаша*/ аркасында ул күп кыенлыклар да күрә. Сабакташлары сөйләвенчә, булачак шагыйрь, кичләрен сәндерәгә ятып, түшәмгә аягын терәп еш кына түбәндәге юлларны кабатлый торган була:

Замана кара булды,
Кабык манара булды.
Какдым казык-үтмәде,
Тукмак әвәрә булды.

Бу эпизод үзе генә дә Шәмсетдиннең бу вакыттагы рухи хәлен ачык күрсәтә. Әмма ул төрле кыенлыкларга да карамастан, укуын уңышлы дәвам итә.

17 яшьләр тирәсендә Шәмсетдин Ашкадар-Балыклыдагы Габдерахман хәзрәт мәдрәсәсенә күчә. Биредә биш ел уку дәверендә ул «Корьән»не тулысынча ятлауга ирешә, география, фикъһе һәм башка фәннәрне ныклап өйрәнә. Әмма яшь егетне

авыл мәдрәсәләре генә кызыксындырмый: аны Казан тарта! Ләкин анда ничек эләгергә? Бервакыт Габдерәхмән хәзрәткә Казан ягыннан Мәүләкәй исемле бер ахун кунакка килә. Ул шәкертләрнең укуы белән кызыксына. Дәресләрдә Шәмсетдиннең «саф зиһенле вә тугры сүзле булуына вә… вә дөрес җавап бирүенә гаҗәпләнеп, Суфыйны бер аулак урынга алыб хәлен камил сорашкан». Булачак шагыйрь аңа үзенең укуы, уй-теләкләре хакында сөйли. Һәм тиз арада Шәмсетдиннең Казанга китү мәсьәләсе хәл кылынган.

Менә 23 яшьлек егет Казанда.  Мәүләкәй ахун ярдәмендә ул биредәге Мөхәммәдкәрим бине Мөхәммәдрәхим мәдрәсәсенә укырга керә.Тиз арада ул үзенең белеме, сәләте, туры сүзле булуы белән күзгә ташлана, мәдрәсә шәкертләре һәм укытучылары арасында  күренекле кешегә әверелә, һәм бераздан, хәлфә булып, үзе дә дәресләр бирә башлый. Бу елларда Ш.Зәкинең кайбер күренекле галимнәр белән дә бәйләнештә торуы мәгълүм. Казан университетының мәшһүр профессоры А.К.Казембек яшь Шәмсетдиннең белем-сәләтенә югары бәя бирә.

Үз кулы астындагы кешенең мөстәкыйльлеге, авторитеты, гыйлемлеге Мөхәммәдрәхим хәзрәттә көнчелек уята. Ике арада каршылык көчәйгәннән-көчәя бара, һәм ул Шәмсетдиннең мәдрәсәдән чыгарылуы белән хәл ителә.

30 яшьләрендә туган авылы Зәккә кайта. Авыл халкы аңа мәдрәсә бинасы төзеп бирә.  Шагыйрь шунда укыта башлый. Аның дәрес әйтүе, мәдрәсәсе тиз арада шөһрәт казана. Бу хакта З.Мөхәммәдрәхими менә ничек яза: Зәккә төрле яклардан, «Сакмар вә Идел буйларыннан, башкорт-бөрҗән таифәләреннән ике йөзгә якын шәкерд җыелган. Һәм дә Суфый хәзрәт Казанда вакытында үзендә укыган Йосыф, Гыйззәтулла, Шәмсетдин намендә улган шакердләр дә килмештер. Җәй фасылларында һәнүз гыйлемдә мәхәббәтләре улган башкорт таифәсендән улган шакедләр мәсҗед ихатасында киез өй (тирмә) корыб укыб ятканлар».

Мәгълүм булганча, Ш.Зәки, сукырлык аркасында, үзе укый һәм яза алмый. «Күзе юкдин язалмады», - ди аңа багышланган мәдхиясендә Г.Чокрый.

Ишетү, тыңлау белем-мәгълүмат туплауда Ш.Зәки өчен төп юл. Шуның өчен ул кирәк китапларны, еш кына башкалардан укытып, үзе тыңлый торган була. Шагыйрьнең һәр төрле язмалары да, әйтеп торып, башкалар кулы белән язылган. Уку-язу эшендә аның төп ярдәмчеләре үз шәкертләре булган. Болардан аеруча Заһиреддин бине Мөхәммәдгали әл-Баимины күрсәтергә кирәк. Ул өч ел буе Ш.Зәки белән бер бүлмәдә яши, аңа көндәлек тормышында булыша; үз остазының әдәби, гыйльми әсәрләрен, төрле фикерләрен кәгазьгә теркәп бара. Шагыйрь, әгәр дә күңеленә берәр нәрсә килсә, үз шәкертенә: «Мелла Заһреддин, каләмеңне ал … пушта килде», - дип дәшә торган була. Каләме үткен бу шәкерт, хәлфә булгач та, үз остазына ярдәм итүен ташламый.

Зәктә өч ел эшләгәч,Ш.Зәки үзенең  һәммә шәкерте белән Эстәрлебашка күчеп китә.

Ш.Зәки күчеп килгән Эстәрлебаш үзенең мәдрәсәләре белән Идел-Урал буйларында мәшһүр була. Аларда татарлар гына түгел, ә башкорт, казах һәм башка төрки халык вәкилләре дә белем ала. Мәсәлән, 19 гасырның 40нчы елларында казах ханы Җиһангирның бер улы Эстәрлебашта укый. Биредә үз дәверенең Гаделшә бине Габдулла  Богданов, Нигъмәтулла бине Биктимер бине Тукай, Мөхәммәд Харис, Гали Чокрый, Мөхәммәтсәлим Өметбаев кебек күренеклк кешеләр эшли. Күп кенә китаплар языла, күчерелә. Шулай ук Эстәрлебашка чит ил басмаларының китерелүе дә мәгълүм. Мәсәлән, Мөхәммәд Харис 1860 елда хаҗ сәфәреннән «күп китаплар алып кайтты» диелә «Тарихе Эстәрлебаш» китабында.

Эстәрлебаш мәдрәсәләрендә рус теле, география һәм кайбер башка дөньяви фәннәр дә билгеле бер күләмдә укытылган. Әмма төп урынны гарәп һәм фарсы телләрен укыту һәм дин сабаклары алып торган.

Ш.Зәки Эстәрлебашта Мөхәммәд Харис (1810-1870) мәдрәсәсендә эшли. Төрле предметлар укыта. Тиз арада ул күп кенә шәкертләрнең яраткан остазына әверелә. Алар арасында Мифтахетдин Акмулла да (1831-1895) була. Ул үз остазының әсәрләрен кәгазьгә теркәүгәбулышкан. Бу ике талантны, иң беренче чиратта, шигърият дуслаштырган. Ш.Зәкинең тирән белемлелеге, чичәнлеге, табигый сәләте, аз сүз белән күп мәгънә белдерүе яшь шагыйрьгә нык тәэсир иткән. Хәтта берничә дистә еллар үткәч тә, Акмулла үз остазын зур хөрмәт белән искә ала һәм шигырьләрен дә аның «мәкаме вә авазы илә» укуын искәртә торган була. Шагыйрь Эстәрлебашта 4 ел чамасы эшли. Зәк-Ишмәт кешеләре җыелып киңәшә дә Ш.Зәкинең кире үзләренә кайтуын үтенәләр. Шагыйрь бераздан аларны үтенечен кабул итә: гаиләсе һәм шәкертләре белән Зәккә кайта.

Ш.Зәки Эстәрлебаштан кайткач, якташлары аңа кечерәк кенә йорт салуда, хуҗалык алып баруда ярдәм итәләр. Шагыйрьне байлык кызыксындырмый, матди яктан ул шактый тыйнак тормыш алып бара. Еш кына әдип тиешле хәер-сәдакалардан баш тарта, яисә: « Фәлән кеше миннән мохтаҗрак, шуңа бирегез!» - дип башкаларга бирдертә торган була.

Ш.Зәки тормыш өчен кирәкле күп кенә нәрсәләрне үзе ясаган. Бу хакта аның кече замандашы Габдулла ибне Харис әл-Эстәрле менә болай яза: «Шәмсетдин Суфыйны гүзәл белерем: Эстәрлебаш карьясендә озын вакыт дәрес әйтде…дөнья һөнәрләреннән вә кул эшләрендән һич белмәдеге нәрсәсе юк иде дисәң, һич арттыру булмас; һич күрмәдек хәлдә сәгатьләрне сүтәр вә соңра кире һәр нәрсәне үз урынына урнаштырыб төзәр вә сәгать тә йөри башлар иде. Китабы күп иде…»

Ш.Зәки чичән табигатьле кеше була. Аның кече яшьтән үк теге яки бу вакыйга уңае белән шигырьләр әйтүе мәгълүм.

Ш.Зәки тормышта сирәк очрый торган искиткеч хәтерле, зиһенле кешеләрнең берсе була. Сөйләүләргә караганда, ул бер ишеткән нәрсәне, сөйләшкән кешесен һич тә онытмаган, күзле кайбер кешеләрдән күбрәк, кызурак йөргән. Халыкта моңа мөнәсәбәтле төрле вакыйгалар сөйләнә. Ашказар- Балыклы авылында укыгандаШәмсетдин 20 чакрым ераклыктагы Коры Киртә авылына еш кына берүзе барып-кайтып йөри торган була. Анда шагыйрьнең Хафиза апасы һәм Ибраһим җизнәсе яши.Ашказар-Балыклының Шаһмөхәммәд исемле бер кешесе, Ш2мсетдинне сынар өчен, ул узачак юл кырыена барып ята. «Суфый исә юлдан таягы илән йөгереп килгәндә, мәзкүр Шаһмөхәммәднең якынына килгәч дә: «Әссәламегаләйкем, Шаһмөхәммәд абзый, монда нишләб ятасың?»- дигән. Шаһмөхәммәд исә: «Сине күрми диб әйтәләр иде, күрәсең икән»,- дип җавап бирә. «Күңел күзе күргәч, заһир күзенең күрмәве зарар бирми»,- дигән дә юлында булган. Икенче бер вакыйгада14-15 яшьлек Шәмсетдиннең Котлыкилде мәдрәсәсеннән 50 чакрым ераклыктагы Эстәрлебаш авылына бер көнне барып, икенче көнне әйләнеп кайтуы бәян ителә.

Тырыщлыгы, табигый сәләте һәм кызыксынучанлыгы аркасында Ш.Зәки үз дәвере татар җирлегенең иң гыйлемле һәм эрудицияле кешеләренең берсенә әверелә. Гарәп һәм фарсы телләрен ул, үз ана теле кебек, шигырьләр һәм гыйльми әсәрләр «язарлык» белә. Фарсы классигы Хафиз Шираз шикелле Ш.Зәки дә «Корьән»нең остасы хисаплана, бу дини китапны һәм аңа шәрехләрне яттан белә. Хәтта кайбер риваятьләр шагыйрьнең Казан руханиларына «Корьән»нең бер басмасындагы ялгышларны күрсәтеп бирүен дә сөйлиләр. Ш.Зәки Шәрык

фәлсәфәсен һәм әдәбиятын яхшы үзләштерә. Язган әсәрләре – моның ачык дәлиле. Чыганаклар шагыйрьнең математика, химия, астрономия («гыйльме һәйәт»), музыка һәм кайбер башка фәннәрдән шактый хәбәрдар булуын күрсәтәләр.Өстәвенә Ш.Зәки гаҗәеп матур тавышлы җырчы һәм сөйләүче дә була. Аның чыгышларын кешеләр һәрчак әсәрләнеп, онытылып тыңлаганнар.

Хаҗга бару – 17-19 гасыр татар укымышлылары һәм руханилары арасында киң таралган күренеш. Хаҗга, әлбәттә, дингә, ислам диненә инанучылар барган. Моны һич тә онытырга ярамый. Әмма мәсьәләнең икенче ягы да бар. Хаҗ сәфәре башка халыкларның һәм илләрнең тормыш – көнкүрешләре, тарихи һәм культура истәлекләре белән танышырга, дөньяны, аның шәһәр-авылларын, диңгез-сәхраларын күрергә мөмкинлек биргән, киңрәк дөньяга чыгуның мөһим бер каналы да булган. Хаҗ сәяхәте Шәрыкның рухи казанышларын күрсәтергә, андагы китап-кульъязмаларны, фольклор хәзинәләрен дә Идел-Урал буйларына алып кайтырга юл ачкан. Күп кенә хаҗилар (Мортаза әс-Симети, Мөхәммәд Әмин, Әбелмәних Каргалы, Гали Чокрый һ.б.) юлда күргән, ишеткән, кичергән нәрсәләрен «сәяхәтнамә», «сәфәрнамә» рәвешендә язып та калдырганнар. Әдәби һәм тарихи чыганак буларак бу истәлекләрнең хәзер дә әһәмиятләре зур.

Хаҗ сәфәре, әлбәттә, зур чыгымнар, сабырлык, түземлек таләп иткән. Кайберәүләр, бөлеп,кайтырга мөмкинлеге булмау аркасында, чит-ят җирләрдә торып та калганнар. Юлда ачлыктан һәм сусызлыктан, төрле авырулардан үлүчеләр дә шактый булган (Мәүлә Колыйның остазыМелла Мамай, Әбелмәних Каргалы, Г.Курсавый, Ш.Зәкинең әтисе һ.б.). Юлбасарлар кылычыннан һәлак булу очраклары да бар, ә инде хаждан туган иленә исән-сау әйләнеп кайтучылар мөселман руханилары укымышлылары арасында шөһрәт белән файдаланганнар: алар дөнья күрүчеләр итеп исәпләнгән. Хаҗга хәтта икешәр-өчәр мәртәбә баручылар да булган.

1850 елларда Ш.Зәки дә хаҗга барырга ниятли. Әмма әүвәл моны тормышка ашырырга мөмкинлек булмый. Юлга акча туплауга, гаилә өчен азык-төлек әзерләүгә, хуҗалыкны эзгә салуга берничә ел кереп китә. Дуслары һәм якыннары, «мондый ерак сәфәр синең өчен куркыныч» дип шагыйрьне хаҗга бару уеннан кире димлиләр,әмма ул үз ниятеннән баш тартмый. Моңа кадәр дә дөнья гизүне, хәрәкәтне үз шигырьләрендә мактаган шагыйрь, үгетләүчеләргә җавап итеп, болай ди:

Бәне үлем илә тәһдид итмәңез,
Чөнки бу үлем бәңа дошман дүгел.

1865 елның сентябрь азакларында Ш.Зәки авылдаш дусты Сафиулла бине Госман һәм Ашкадар буендагы Явыш авылы кешесе Кинҗә Морза белән хаҗ сәфәренә чыгып китә.Диңгезгә кадәр алар, нигездә, җәяүләп баралар. Әмма Азов буендагы Таганрог шәһәренә җиткәч, Ш.Зәки, кинәт авырып, васыятьләрен дә әйтә алмыйча, үлеп китә. Мөгаен, аны йөрәге тоткандыр.Чөнки йөрәге авыру булуын шагыйрь үз әсәрләрендә дә телгә алгалый. Таганрогның бер күмәчче мишәр татары Ш.Зәкине үз йортына алдыра, кадер-хөрмәт белән мәрхүмне күмүне оештыра; хәтта кем һәм кайдан икәнлеген күрсәтеп, кабере өстенә таш та куйдыра, әмма шагыйрьнең кабере һәм куелган таш хәзергәчә сакланмаган. Ул кайчан юкка чыккандыр,-билгесез. Таганрог крайны өйрәнү музееның гыйльми хезмәткәре Н.М.Князюк: «Кызганычка каршы, Таганрогтагы мөселман зияраты сакланмаган. Русларның иске зиярятында да Шәмседдин Зәкинең каберташын таба алмадык»,- ди.

Шулай итеп, шагыйрь туган җиреннән читтә ятып кала. Аның юлдашлары хаҗга юнәләләр, әмма бу сәфәр алар өчен дә уңышлы булмый. Кинҗә Морза, материаль кыенлык аркасында, ары бара алмый: Истанбулда торып кала. Аның туган йортына

кайтырга мөмкинлеге булмый: каберен дә ул шунда – Төркиядә таба.Сафиулла исә Мәккәгә барып җитә, әммма кайтышлый ул да үлеп китә.Аның гәүдәсен диңгезгә ташлыйлар. Бу хакта Зәк-Ишмәтнең өлкән кешеләре әле хәзер дә сөйлиләр. Кайбер чыганаклардан Сафиулланың юлда күргәннәрен сәяхәтнамә («сәфәрнамә») рәвешендә язып баруы мәгълүм. Ш.Зәкинең һәм үзенең кайбер әйберләре белән берлектә бу кульъязма Зәк-Ишмәткә килеп җитсә дә, бераздан ул, ниндидер сәбәпләр аркасында, юкка чыга. Ш.Зәки 1865 елның ноябрь урталарында үлгән. Туу вакыты 1821 елның гыйнвар башларында.

Ш.Зәки үз гомеренең өчтән береннән артыграгын укыту эшләренә багышлый. Шушы вакыт эчендә ул Идел-Урал регионының төрле төбәкләреннән чыккан күп санлы шәкертләр тәрбияли. Аларның шактые үз дәверенең һәм җирлегенең билгеле генә кешеләренә әверелә (Хөснеддин бине ГайнеддинМостафави, Заһиреддин бине Мөхәммәдгали әл- Бөрҗани, Шәмсетдин Җаекый һ.б.). Ш.Зәки шәкертләре арасында мәшһүр Акмулладан тыш, иҗат эше белән шөгыльләнүче башкалар да була.

Шәмсетдин Суфый Зәки – педагог, галим һәм оригиналь шәхес булу белән беррәттән, төрле жанрларда иҗат ителгән күп санлы әдәби әсәрләр авторы да.Күп кенә элгәрләре һәм чордашлары кебек үк, ул да дингә ышана,аллага сыгына. Шагыйрь өчен алла – табыну,сыгыну чыганагы гына түгел, ә хаклык, хакыйкать идеалы да.Күп кенә суфый әдипләрдән үзгә буларак,Ш.Зәки танып-белү процессында,кеше яшәешендә гакылны беренче планга куя,аңа югары бәя бирә.

Ш.Зәки иҗатында төп урынны газәлләр алып тора.Әдип шигырьләренең 40 проценты диярлек (299 бәет) шушы жанрда иҗат ителгән.Ул мәдхия, робагый,кыйтга,хикмәтле сүз,фәрд кебек поэтик жанрлардан да иркен файдалана. Әдип әсәрләренең һәммәсе диярлек лирик жанрда.Аларның үзәгендә хис-тойгылар, уй-кичерешләр. Бер-берсе белән тыгыз бәйләнешле бу парчалар төрле халәттәге шагыйрь күңеленең поэтик сурәтләре булып торалар.

Шагыйрь иҗатында арттыру,сынландыру, антитеза, янәшәлек һәм әдәби мирастагы башка төрле чараларны уңышлы куллана.

Шигырьләре аркылы Ш.Зәкинең көчле әдәби талантка ия булуын,Урта гасыр Шәрык һәм татар мәдәни казанышларын әйбәт белүен абайлау кыен түгел.Аның шигырьләренә фәлсәфи тирәнлек, нечкә лиризм,уй-кичерешләрнең бөтенлеге, шигъри камиллек хас.Нәкъ менә шул сыйфатлар шагыйрь әсәрләренең әдәби-тарихи кыйммәтен күтәрә, популярлыгын арттыра.

Шәмсетдин Зәкинең исеме мәңгеләштерелгән.
1993 елда Зәк-Ишмәт авылы урта мәктәбендә мемориаль такта куелды.
Туган авылында бер урам Шәмсетдин Зәки исемен йөртә. Шул урамда Гафур чишмәсе тәртипкә китерелде.
*Слайдлар 2,3,4*

Кулланылган әдәбият.

1. Х.Миңнегулов, Ш.Садретдинов «19 йөз татар әдәбияты ядкярләре»,Казан университеты нәшрияты,1982
2. М.Х.Гайнуллин «Татар әдәбияты 19 йөз», Казан, 1968
3. Татарская энциклопедия, Казан,2005
4. Ризаэддин Фәхреддин «Асар», Казан, 2009